**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2020елның 15 июне** **№ 150**

**Дүртенче чакырылыш «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Куйбышев Затоны штп , Ульяновск шоссесы 12;

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Куйбышев Затоны штп , Куйбышев ур., 2А;

ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Куйбышев Затоны штп, Парковая ур.3

3. “Идел таңнары” газетасында әлеге карарны кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы** **Н. Б. Ефимов**